ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 155

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

2022 елның 29 августы

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2022 елның 1 мартындагы 35 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсус коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан белешмәләр тапшыру тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актның аерым нигезләмәләренә төзәтмәләр кертү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2022 елның 1 мартындагы 35 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсус коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан белешмәләр тапшыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Махсус счет хуҗасы ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр кәгазь чыганакта, шулай ук Excel форматында электрон рәвештә электрон почта аша яки ТР ТФМ ДМС ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне ТР ДТИ тапшыра (4 нче кушымта):».

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны җитәкче урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С.Саттаровка йөкләргә.

Җитәкче С.А. Крайнов